ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

26 10 2020 г. № 823

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 24 июлендәге 474 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

2018 елның 25 декабрендәге «Һәвәскәр балыкчылык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 475-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә карар бирәм:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 24 июлендәге 474 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану кагыйдәләренә кертелә торган кушымта итеп бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны матбугат басмасында һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.М.Шәйдуллинга йөкләргә.

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 26 нчы октябрь
823 нче номерлы карары белән расланган
кушымта

. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 24 июлендәге 474 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану кагыйдәләренә кертелә торган үзгәрешләр

1. «Гомуми нигезләмәләр» 1 бүлегендәге 1 пунктның 7 абзацында «һәвәскәр» сүзеннән соң «һәм спорт» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. «Гомуми таләпләр» II бүлегендәге 1 пунктның 4 абзацында «һәвәскәр ... гамәлгә ашыру өчен» «һәм спорт» сүзләрен төшереп калдырырга.

3. V бүлек. Һәвәскәр һәм спорт балыкчылыгы өчен урыннар сайлауга таләпләрне яңа редакциядә бәян итәргә:

«V. Һәвәскәр балыкчылык өчен урыннар сайлауга таләпләр

1. Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең гомуми файдаланудагы су объектларында һәвәскәр балыкчылык «Балыкчылык һәм су биологик ресурсларын саклау турында» 2004 елның 20 декабрендәге 166-ФЗ номерлы Федераль закон, «Һәвәскәр балыкчылык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 25 декабрендәге 475-ФЗ номерлы Федераль закон һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла

2. Балык тоту тыела:

- шартлаткыч, агулый торган матдәләр, электр тогы, кадый торган тоту кораллары, су асты аучылыгы өчен коралдан тыш, ятьмәләр һәм балык тоту кирәк-яраклары, барлык конструкциядәге тозаклар, кармаклы ятьмә файдаланып, балыклар күпләп җыелу урыннарында ыргаклау, асма селкенмә алдавыч кую, балыкны миңгерәйтү, томалау һәм башка төр киртәләр кую, сулыкларны агызу ысулы белән;

- халык күпләп була торган һәм оештырылган ял итү урыннарында су асты аучылыгы өчен корал кулланып, уылдык чәчү чорында ярдан, суда йөзү чарасы бортыннан, йөзеп кереп, акваланг һәм башка автоном сулыш приборлары кулланып.

3. Сулыкларда һәм су саклау зоналарында шартлаткыч, агулы матдәләр һәм тыелган балык тоту кораллары белән, шулай ук һәвәскәр балыкчылык тыелган яр буе зоналарында теләсә нинди балык тоту кораллары һәм су биоресурслары тотымы белән булу тыела.».